РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Главы
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 30, Азнакаевский район,
п.Победа, 423312,
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 30 йорт, Азнакай районы, Җиңү
бистәсе, 423312,
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«27» сентябрь 2023 ел.** **№ 7**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Уставының 15.1 ст. нигезендә Азнакай муниципаль районының «Вахит авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авылы җирлеге Чәкән торак пунктында Базарлы урамы буенча 1 йорттан 27 йортка кадәр, Бәйрәкә урамы 1 йортан 17/2 йортка кадәр сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2024 елга халык җыенын 2023 елның 13 октябрендә 10 сәгать 00 минутка беренче этабын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлегенең Чәкән торак пунктында Зур урамы буенча 1 йорттан 27 йортка кадәр, Комаровка урамы 1 йортан 21 йортка кадәр, Кечкенә урам буенча барлык йортлар, Яңа урам буенча 1 йорттан 25 йортка кадәр сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2024 елга халык җыенының 2023 елның 13 октябрендә 11 сәгать 00 минутка икенче этабын билгеләргә.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлегенең Чәкән торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлегенең Башкарма комитетын;

гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты - 2023 елның 13 октябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
-гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү урыны - Чәкән авылы мәдәният йорты бинасы, адресы буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Чәкән авылы, Базарлы ур., 23 йорт.
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү урыны - Чәкән авылы мәдәният йорты бинасы, адресы буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Чәкән авылы, Базарлы ур., 23 йорт.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсъәләне түбәндәгечә расларга:
"Сез 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 1400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:
1) Чәкән торак пунктында  урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;
2) Чәкән торак пунктында  рус һәм татар зираты территориясен төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;
3) Чәкән торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
4) халыкның күплəп ял итү урыннарын төзекләндерү, аларга якын урнашкан Чәкән торак пунктын төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6.  Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Вахит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.
7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Г.И. Әскәрова